**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«1» март 2021 с. Тюлячи № 85

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләре турында

Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы буенча гражданнар оборонасы өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы консультантының 2021 елның 16 февралендәге хатын карап, «Балыкчылык һәм су биологик ресурсларын саклау турында» 2004 елның 20 декабрендәге 166-ФЗ номерлы Федераль закон, «Һәвәскәр балыкчылык турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 25 декабрендәге 475-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 28 өлеше, Россия Федерациясе Су кодексының 6 статьясындагы 3 пункты, 27 статьясындагы 4 пункты нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану Кагыйдәләрен кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Ф.С. Вәлиевка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Кушымта

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«01» 03. 2021 № 85
карары белән расланган

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану Кагыйдәләре

Әлеге Кагыйдәләр «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнелгән, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану өлкәсендә бердәм, мәҗбүри нормаларны һәм таләпләрне билгелиләр.

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Кагыйдәләрдә кулланыла торган төп төшенчәләр:

- *су объекты* - суларның характерлы формалары һәм су режимы билгеләре булган табигый яисә ясалма сулык, су агымы йә суларның даими яисә вакытлыча туплануы булган башка объект;
- *яр буе полосасы* - гомуми файдаланудагы су объектының яр линиясе буйлап җир полосасы; су объектлары өчен яр буе полосасының киңлеге Россия Федерациясе Су кодексы белән билгеләнә;
- *гомуми кулланылыштагы су объекты* - әгәр су законнарында башкасы каралмаган булса, һәркем файдалана алырлык су объекты булган дәүләт яисә муниципаль милектәге җир өсте су объекты;
- *су саклау зонасы* - хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыруның махсус режимы билгеләнә торган су объектының яр линиясенә тоташа торган территория, су объектларын пычратуны, чүпләүне, ләмне һәм аларның суларын агызуны булдырмау, шулай ук су биологик ресурсларының яшәү тирәлеген һәм хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының башка объектларын саклап калу максатларында; су объектларының су саклау зонасы киңлеге Россия Федерациясе Су кодексы белән билгеләнә;
- *су объектларыннан файдалану (судан файдалану)* - Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең, физик һәм юридик затларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен төрле ысуллар белән су объектларыннан файдалану;
- *шәхси, гаилә, йорт ихтыяҗлары* - эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле булмаган, үз эченә коену, бакча, яшелчәчелек, дача җир кишәрлекләрендә сулау, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, шулай ук су алу, авыл хуҗалыгы һәм йорт хайваннарын карау эшләрен башкару, һәвәскәр балыкчылык һәм аучылык, йөзү һәм физик затларның хосусый милкендәге һәм эшкуарлык эшчәнлеген

гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган йөзү чараларын алган шәхси, гаилә һәм йорт ихтыяҗлары;

- *яр буе саклау полосасы* - хуҗалык һәм башка эшчәнлеккә өстәмә чикләүләр кертелә торган су саклау зоналары чикләрендәге территория;

- *агынты сулар* - яңгыр, кар, инфильтрация, су сиптерү, дренаж сулары, аларны су объектларына чыгару (ташлау), кулланганнан соң гамәлгә ашырыла торган үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу системасыннан чыккан һәм башка сулар.

## II. Гомуми таләпләр

1. Һәр граждан, әгәр Россия Федерациясе Су кодексы, башка федераль законнарда башкасы каралмаган булса, гомуми файдаланудагы су объектларына башкалар кебек керү хокукына ия һәм аларны шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен түләүсез файдалана ала.

Гражданнар хокуклы:

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан ял итү, туризм, спорт, һәвәскәр балыкчылык, һәм дача кишәрлекләренә су сибү, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен, әлеге кагыйдәләр белән билгеләнгән тәртиптә су объектларыннан файдалану белән бәйле башка максатларда файдалануга;

- гомуми файдаланудагы су объектларының яр буе полосасыннан хәрәкәт итәргә (механик транспорт чаралары кулланмыйча) һәм алар янында булырга шул исәптән һәвәскәр балыкчылык һәм йөзмә чаралар өчен причал ясауга файдаланырга;

- су законнары нигезендә гомуми судан файдалану.

2. Шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдаланганда гражданнар:

- су объектыннан файдалануны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән нигезләрдә гамәлгә ашыручы су кулланучыларның хокукларын чикләргә, шулай ук кешеләр өчен киртә булырга һәм куркыныч тудырырга тиеш түгел;

- су объектларын саклау кагыйдәләрен белергә һәм үтәргә тиеш;

- Россия Федерациясе законнарында, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән гомуми судан файдалану таләпләрен үтәргә тиеш;

- габаритлы озынлыгы 20 метрдан ким булган судноларның, пляжлар тирәсендә, суда халыкның күпләп ял итү районнарында җилкәнле спорт һәм сәяхәт итү судноларының тизлек режимы сәгатенә 12 км дан да артмаска тиеш, ә елга портлары акваторияләрендә, ясалма каналларда, торак пунктлар чикләрендә, суднолар туктап тору районнарында – сәгатенә 15 км дан артык түгел.

3. Шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдаланганда тыела:

- су объектларына ташлау һәм аларда җитештерү һәм куллану калдыкларын, шул исәптән эксплуатациядән чыгарылган судноларны һәм башка йөзү чараларын (аларның өлешләрен һәм механизмнарын) күмү;

- су объектларына рөхсәт ителгән йогынтыдан артып китүче, радиоактив матдәләр, пестицидлар, агрохимикатлар һәм кеше сәламәтлеге өчен куркыныч булган башка матдәләр һәм кушылмалар булган башка суларны агызу;

- атом-төш материаллары, радиоактив матдәләрне су объектларында күмү;

- су объектының санитар кагыйдәләргә һәм халыкның сәламәтлеге өчен гомуми файдаланудагы су объектыннан файдаланудагы куркынычсызлык шартларына туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә булмаганда, коену;

- кисәтүче яки тыючы язулар белән махсус мәгълүмати билгеләр куелган урыннарда коену;

- ягулык-майлау материалларын яр буе полосасында саклау;

- кер юу, башка мөлкәт юу һәм кешеләрне коендыру өчен билгеләнгән урыннарда хайваннар коену, һәм алардан 500 метрга кадәр озынлыкта;

- транспорт чараларының (махсус транспорт чараларыннан тыш) хәрәкәте һәм туктап торуы, аларның юллар буйлап йөрүләреннән, юлларда һәм махсус җиһазландырылган, каты өслекле урыннарда тукталуларыннан тыш;

- гомуми файдаланудагы су объектларында һәм аларның яр буе полосасында автотранспорт чараларын һәм башка техниканы юу;

- су объектының санитар кагыйдәләргә һәм халыкның гомуми файдаланудагы су объектыннан файдалану өчен куркынычсызлык шартларына туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә булмаганда, эчә торган һәм хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү максатларында су алу;

- әйләнә-тирә мохиткә зыян китерүче, кешеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы гамәлләр кылу;

- махсус мәгълүмат билгеләрен үз белдегең белән алып ташлау, зарарлау яки юк итү.

4. Кече күләмле судноларда йөзү өчен су объектларыннан файдалану Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Россия Федерациясенең су объектларында кече күләмле судноларда файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2005 елның 29 июнендәге 502 номерлы боерыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече үлчәмле судноларда йөзү өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2007 елның 15 октябрендәге 562 номерлы карары белән билгеләнгән таләпләрне үтәп гамәлгә ашырыла.

5. Кеше тормышына һәм сәламәтлегенә зыян китерү куркынычы янаган очракларда, радиация авариясе яки табигый-техноген характердагы башка гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгәндә, әйләнә-тирә мохиткә зыян китерелгәндә, гидроэнергетика объектларының саклау зоналарын билгеләгәндә, шулай ук федераль законнарда каралган башка очракларда, судан файдалану Россия Федерациясе Су кодексы белән каралган тәртиптә туктатылырга яисә чикләнергә мөмкин.

## III. Шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен су алуга таләпләр

1. Эчү һәм хуҗалык-көнкүреш максатлары өчен пычранудан һәм чүпләнүдән сакланган гомуми файдаланудагы су объектлары кулланылырга тиеш, әлеге максатлар өчен гомуми файдаланудагы суның яраклылыгы законнар нигезендә санитар-эпидемиологик бәяләмәләр буенча билгеләнә.

2. Су кулланучыларга зыян китерә торган күләмдә бакча, яшелчә, дача җир кишәрлекләренә су сибү, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, шулай ук су эчертү өчен, башка авыл хуҗалыгы хайваннарын карау эшләрен башкаруга су җыю тыела.

## IV. Коену өчен билгеләнгән урыннарга таләпләр

1. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гомуми файдаланудагы су объектларында кешеләрнең коенуы «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Гомуми файдаланудагы су объектларыннан һәм янәшәдәге территорияләрдән файдаланганда тыела:

- тыю билгеләре һәм язулары булган щитлар (аншлаглар) куелган урыннарда коенырга;
- йөзү чикләрен билгеләүче калкавычлардан йөзеп чыгарга;
- моторлы, җилкәнле судноларга, ишкәкле көймәләргә һәм башка суда йөзү чараларына йөзеп якын килү;
- суга катерлардан, көймәләрдән, причаллардан, шулай ук әлеге максатлар өчен яраксыз корылмалардан сикерү;
- су объектларын һәм ярларны пычратырга һәм чүпләргә;
- исерек хәлдә коенырга, спиртлы эчемлекләр эчәргә;
- үзең белән эт һәм башка хайваннар алып килергә;
- чүп-чарны яр буенда һәм киенү-чишенү кабиналарында калдыру;
- бу максатларга туры килмәгән урыннарда туп белән һәм спорт уеннары уйнау, шулай ук чуму һәм коенучыларны су астыннан тоту, ялган шом салу;
- такталарда, бүрәнәләрдә, ятакларда, автомобиль камераларында һәм моның өчен махсус яраклаштырылмаган башка әйберләрдә йөзәргә;
- су объекты территориясенә механик транспорт чарасында керергә, шулай ук аны юарга;
- су объекты акваториясенең кызгылт сары төстәге калкавычлар белән билгеләнгән мәйданы чикләрендә, гражданнарның коену урыннарына якын урыннарда балык тоту.

## V. Һәвәскәр балыкчылык өчен урыннар сайлауга таләпләр

1. Татарстан Республикасының «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми файдаланудагы су объектларында һәвәскәр балыкчылык «Балыкчылык һәм су биологик ресурсларны саклау турында» 2004 елның 20 декабрендәге 166-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Балык тоту тыела:

- су астында балык тоту коралларыннан тыш, шартлаткыч, агулый торган матдәләр, электр тогы, кадап тоту кораллары, ятьмәләр һәм балык тоту җиһазлары, барлык аулау конструкцияләре, кармаклы ятьмә кулланып, балык күплэп җыела торган урыннарда багрение ысулы белән, асылмалы ялтыравык тимер файдаланып, ятьмә белә тоту;
- халыкның күплэп һәм оешып ял итә торган урыннарында ярдан, йөзү чаралары бортыннан, су асты аучылыгы өчен корал, акваланг һәм башка автоном сулыш приборлары кулланып, уылдык чәчү чорында балык тоту.

3. Сулыкларда һәм су саклау зоналарында шартлаткыч матдәләр, агулаучы матдәләр һәм тыелган балык тоту кораллары белән булу тыела, шулай ук һәвәскәр

балыкчылык тыелган яр буе зоналарында теләсә нинди балык тоту һәм су биоресурсларын тоту җиһазлары белән.

## VI. Авыл хуҗалыгы хайваннары өчен су эчертү урыннарын сайлауга карата таләпләр

1. Кешеләр коену өчен билгеләнгән урыннарда авыл хуҗалыгы хайваннарына су эчертү, аларны коендыру тыела.

2. Авыл хуҗалыгы хайваннарының су керү һәм коену урыннары кешеләрнең ял итү һәм коену зоналарыннан 500 метрдан да ким булмаган ераклыкта урнаша.

## VII. Халыкка һәм җирле үзидарә органнарына хәбәр итү

1. Татарстан Республикасы «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан су объектларында судан файдалануны гамәлгә ашыру шартлары яки чикләү турында мәгълүмат халыкка «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан массакүләм мәгълүмат чаралары аша, махсус мәгълүмати билгеләр һәм башка ысуллар ярдәмендә бирелә.

2. Татарстан Республикасы «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан су объектларындагы аварияләр һәм башка гадәттән тыш хәлләр турында милекчеләр һәм судан файдаланучылар кичекмәстән Теләче муниципаль районының бердәм кизү-диспетчерлык хезмәте аша җирле үзидарә органнарына 112 телефоны аша хәбәр итәргә тиеш.

## VIII. Әлеге кагыйдәләрне бозган өчен җаваплылык

1. Әлеге кагыйдәләрне бозуда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык тоталар.

2. Су законнарын бозган өчен җаваплылыкка җәлеп итү гаепле затларны җибәрелгән хокук бозуларны бетерү һәм алар китергән зыянны түләтүдән азат итми.